СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №133 (7462) | 7 ноябрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

**7 ноябрь— Бөек Октябрь социалистик революциясенә 75 ел**

◆ Бер колхоз хәбәрләре

## Тагын бер бина әзер

«ЗАРЯ» КОЛХОЗЫ. Хуҗалык узган ел сарыклар өчен 350 башка исәпләнгән яңа бина төзеп файдалануга тапшырган иде инде. Әле 2 көн генә элек янә бер бина терлекчеләр карамагына бирелде. 350 башка исәпләнгән бу бинаны техник-төзүче Алексей Исаевич Перепелкин, бригадир Леонид Шкаликов җитәкчелегендә төзүчеләр бригадасы салды. Бригада членнары Малик Хөснетдинов, Олег Михедюков, Виталий Мөхетдинов, Федор Казаков әлеге бинаны яңа кышлату чорына төзеп бетерү өчен бөтен көчләрен куйдылар. Яңа абзарда чабан Владик Анисимович Максюткин яңа группа кабул итте.

## Өстәмә сый кирә

Кырларга органика чыгару буенча районда игълан ителгән удар икеайлыкка хуҗалык беренчеләрдән булып кушылды. Хәзер басуларга 2 мең тоннадан артык өстәмә сый чыгарылды инде. Тиресне төяп торучы Николай Фролов, бульдозерда төрттерүче Аркадий Акмурзин ташудагы транспорт чараларын бер дә тик тотмыйлар. Ә тиресне басуга күчерүчеләр—Валерий Иванов, Александр Гражанов, Николай Андреев, Анатолий Албутов, Николай Морозов, Юрий Иванович Матвеев кырга көне буе берничәшәр рейс ясарга өлгерәләр.

Хуҗалык темпны киметмичә 150 гектар җиргә өстәмә сый кертергә уйлый.

**В. ИШТУЛЛИН.**

**ПАЙЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!**

Октябрь райпосы идарәсе пайчыларны 10 ноябрьгә кадәр идарәгә (**Кооперативная урамы,** 3 йорт, 14 бүлмә) кертелгән пай суммасын раслау өчен килергә чакыра. Үзегез белән паспорт һәм членлык кенәгәсе булу шарт.

Күрсәтелгән срокта теркәү үтмәгән пайчылар райпо милкенә хокукларын югалталар.



Тыныч, сабыр табигатьле Анатолий Богомолов нәкъ авыл хезмәте өчен яратылган да. Күп еллар буена механизатор булып эшләү дәверендә төрлесен татыды, тик беркайчан да зарланганын күрмәделәр аның. Әнә шундый булуы өчен аны машина-трактор паркына бригадир итеп куйдылар да инде. Ул бирәдә дә сынатмады. Хезмәттәшләре арасында уртак тел тапты. Хәзер бирәдә ремонт эшләре башланды, Анатолий өчен аерата киеренке көннәр бу.

Рәсемдә: «Төрнәс» совхозы трактор паркы бригадиры А. Богомолов.

Н. Азизов фотосы.

## Планнар үтәлә

Ремонт-техник предприятиесенең иң мөһим тармагы—тракторлар ремонтлау цехын Михаил Васильевич Белянин җитәкли. Билгеле булганча, Михаил Васильевич бу цех белән 20 елдан артык җитәкчелек итә. Цех һәр елны әйбәт күрсәткечләргә ирешә. Бу цех соңгы берничә елда Т-70 тракторларын капиталь ремонтлау буенча махсуслаштырылган. Бирәдә шулай ук бөртек комбайннары һәм тракторларның дизель двигательләрен ремонтлыйлар. Болардан тыш бу цехта чәчкечләрнең сошникларын, трактор һәм комбайннарның пычакларын ремонтлау эшләре дә бара. Агымдагы елда коллектив план буенча 145 данә Т-70 тракторына капиталь ремонт үткәрергә тиеш иде, алар аны арттырып —156 трактор ремонтладылар. Шулай итеп, 9 айлык планны 107 процентка үтәделәр. Бөртекле культуралар игү өчен 60 комбайн ремонтланырга тиеш булса, 9 айда алар 61 комбайн ремонтлап, планны 101 процентка үтәгәннәр. Пландагы 145 урынына 160 дизель двигателе ремонтланды, бу төр планы 110 процентка үтәлде. Моңа һичшиксез бәтен коллективның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә ирешелде, ремонт эшләре хәзер дә тукталмый. Бигрәк тә механик Минислам Таһирович Мөхетдинов җитәкләгән комбайннар ремонтлау участогында хәзер эшләр кызу бара. Запас частьләрнең җитешмәвенә карамастан, комбайннарны үз вакытында һәм сыйфатлы ремонтлау өчен тырышалар егетләр.

Бирәдә эшләүче Николай Кириллов, Николай Максимов, Геннадий Васин, Геннадий Сидоров, Михаил Смолин коллективның горурлыгы һәм терәге булып торалар.

Ремонт-техник предприятиесенең бурычы бер: —1 апрельгә барлык төр техниканы да сыйфатлы итеп сафка бастыру.

**Н. МИНҺАҖЕВА.**

## Өлкәннәрне кайгыртып

Бер төргәк чит илдә эшләнгән макарон һәм 0,5 килограмм яхшы (цейлон, һинд һәм башка төрле) чәй алачак бу көннәрдә 6150 кеше. Әлеге бәхетлеләр кемнәр соң? Алар—гомуми авыру буенча инвалидлар, бала чактан инвалидлар, Чернобыльдәге аварияне бетерүдә катнашучылар, репрессияләнүчеләр (бездә андыйлар да бар). Ватан сугышы инвалидлары, сугышта катнашучылар, сугышта һәлак булучыларның гаиләләре, ялгыз картлар, яшь буенча пенсиядәгеләр, шулай ук тарәучысын югалтучылар.

Продуктларны бүлү белән район социаль тәэминат бүлеге шөгыльләнә. Шәһәрдә яшәүчеләр якын көннәрдә үк биредән бер тапкыр кулланыла торган махсус талон алып продуктлар ала алалар. Моның өчен үзең белән пенсия таныклыгы гына алып килергә кирәк.

Авыл җирләрендә бу мәсьәлә белән авыл Советлары шөгыльләнәчәк.

## Семинар-киңәшмә үтте

4 ноябрь көнне «1 нче май» колхозы базасында район терлекчеләр семинары үтте. Район терлекчеләренең 10 айлык эш нәтиҗәләрен яктыртуга һәм әлеге хуҗалыкның кышлатуга әзерлек тәҗрибәсен өйрәнүгә багышланган бу семинарда хуҗалыклар җитәкчеләре, зооветбелгечләр, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләре һәм эшкәртү промышленносте вәкилләре, район администрациясе работниклары катнаштылар.

Семинарның практик өлешендә «1 нче май» колхозының җәмәгать терлекчелеген кышлатуга әзерлеге һәм аның барышы каралды. Хуҗалык бу җаваплы чорга тулы әзерлек белән килгән: терлек абзарлары төзек, җылы, азык җитәрлек күләмдә тупланган. Товарлыклы сарыкчылык фермасында да малларны асрау, карау өчен бөтен шартлар каралган, микроклимат яхшы, азык кухнясы өзлексез эшләп тора, азык эшкәртелә, ясалма сөт тә бирелә. Бирәдә бәрәнләтү чорына шәхси һәм группа читлекләре ясалган.

Товарлыклы-дуңгызчылык фермасында да максималь продукция алу өчен бөтен шартлар бар. Үрчем алу турлап оештырылган, биналар җылы, азык цехы өзлексез эшләп тора. Колхозда малларга ашату өчен бәрәңге алдан тупланган, рационда хайваннардан алына торган азыкларга зур урын бирелә, имезүдән аерылган дуңгыз балаларына кызыл балчык һәм минераль азыклар өстәлә.

Семинарда катнашучылар товарлыклы-сөтчелек биналарында да эшнең әйбәт куелышын билгеләделәр. Бирәдә маллар физиологик торышлары буенча группаларга аерылганнар, рацион малларның физиологик торышыннан чыгып төзелә, аларны 6 тапкыр ашату, раздой оештырылган. Маллар барысы да әйбәт көрлектә, савым өч тапкыр үткәрелә. Үрчем алу өчен оптималь шартлар бар. Хуҗалыкта 20 елдан артык ясалма орлыкландыру гамәлдә, хәзер дә пункт эшләп тора. Фермаларга килү юллары, азык дворлары —һәммәсе тәртиптә, терлекчеләрнең ялы өчен тудырылган шартлар да мактауга лаек.

Семинарда «1 нче май» колхозының кышлатуны уңышлы башлап җибәрүендә нәкъ аңа тулысынча әзерлек, омтылышлы эшләүнең роле ассызыкланды һәм бу тәҗрибәне һәр хуҗалыкта да файдалану зарурлыгы билгеләнде.

Семинар-киңәшмәнең теоретик өлешендә район терлекчеләренең 10 айлык эш нәтиҗәләренә анализны авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ә. Н. Рәхмәтуллин ясады. Ул аерым хуҗалыкларның бу юнәлештә бик сүлпән эшләүләрен билгеләп, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм сату буенча район планының үтәлешенә тискәре тәэсирен күрсәтте, ел ахырынача калган арада барлык көчне планнарны уңышлы үтәүгә тупларга чакырды.

Семинарга йомгакны район администрациясе башлыгы Ш. В. Кашапов ясады. Ул бүген терлекчелектә эшләрнең торышына канәгатьсезлек белдереп, бу юнәлештә эшчәнлекне бермә-бер яхшыртырга кирәклегенә басым ясады, якын арага һәм перспектив бурычларны бәян итте.

## Задание чынга аша

Кормыш авыл Советына керүче хуҗалыклар үзләреннән арткан сөтне сатуда актив катнашалар. Бүгенге көнгә дәүләткә 2510 центнер сөт озатылды. Бу шәхси хуҗалыклардагы һәр сыерга 736 килограмм сөт хәзерләнде дигән сүз.

Бүгенге көнгә Кормыш авылыннан Сания Мифтахова 5850 килограмм, Зинаида Андреева 3954, Тәнзилә Җамалова 3484 килограмм, Чишмә авылыннан Сания Вәлиәхмәтова 5517, Зөлкәбирә Әбделмәнова 3920, Гөлсирә Морадыймова 3170 килограмм сөт тапшырдылар. Сөт җыючыларыбыз үз эшләренә җаваплылык белән карыйлар. Кормыш авылыннан Миншакир Җамалов, Чишмә авылыннан Гомәр Галиуллин, Чуваш Мәнҗесеннән Анатолий Платонов, Түбән Норлат авылыннан Энҗе Бикташева, Югары Норлат авылыннан Асия Мөлекова бер көнне дә калдырмый, иртәнге сәгать 5 тән 7 гә кадәр ат белән авылны әйләнеп чыгалар.

## Бакча гөрләп үсәр

**«Кондырча» колхозы.** Колхозның яшелчә бакчасын киңәйтү, аны җиләк-җимеш агачлары белән дә баету турындагы хыял, ниһаять, быел гамәлгә ашарга ошый: колхоз ике гектардан артык мәйданга быел 6 мең төп карлыган утыртты. Бу эшне нигездә Түбән Норлат мәктәбенең хезмәт укытучысы Ш. Әхмәдиев җитәкчелегендә 9—10—11 класс укучылары башкардылар, анда колхоз шоферларының да көче керде.

Киләчәктә бакчага алмагачлар утырту да планлаштырыла.

